**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

_08.10.2015_ __816-п__

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 9 декабрендәге 722-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының, федераль дәүләт күзәтчелегенә тиешле су объектларыннан кала, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, һәм шулай ук судан файдалануның һәм алардан файдалану һәм аларны саклау региональ дәүләт күзәтчелегенә тиешле булган, су объектларында урнашкан гидроэнергетика объектларының саклык зоналары чикләрендә яр полосасы кишәрлекләреннән (шул исәптән гидроэнергетика объектларына тоташкан кишәрлекләрдән) файдалануның аерым шартларын үтәүне региональ дәүләт күзәтчелегендә тотуга карата дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнар белән яраштыру максатларында түбәндәгеләр хакында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 9 декабрендәге 722-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының, федераль дәүләт күзәтчелегенә тиешле су объектларыннан кала, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, һәм шулай ук судан файдалануның һәм алардан файдалану һәм аларны саклау региональ дәүләт күзәтчелегенә тиешле булган, су объектларында урнашкан гидроэнергетика объектларының саклык зоналары чикләрендә яр полосасы кишәрлекләреннән (шул исәптән гидроэнергетика объектларына тоташкан кишәрлекләрдән) файдалануның аерым шартларын үтәүне региональ дәүләт күзәтчелегендә тотуга карата дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына (алга таба – Административ регламент) кертелә торган, кушымта булып килүче үзгәрешләрне расларга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Х.Низамовка йөкләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2013 елның 9 декабрендәге 722-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының, федераль дәүләт күзәтчелегенә тиешле су объектларыннан кала, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, һәм шулай ук судан файдалануның һәм алардан файдалану һәм аларны саклау региональ дәүләт күзәтчелегенә тиешле булган, су объектларында урнашкан гидроэнергетика объектларының саклык зоналары чикләрендә яр полосасы кишәрлекләреннән (шул исәптән гидроэнергетика объектларына тоташкан кишәрлекләрдән) файдалануның аерым шартларын үтәүне региональ дәүләт күзәтчелегендә тотуга карата дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

**(Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2015 елның 08 октябрендәге 816-п номерлы боерыгы белән расланды)**

Административ регламентның 1.1 пунктындагы беренче абзацны “юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата” сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 1.2 пунктында:

өченче абзацта “ТР ЭТРМ министры (алга таба – министр), ТР ЭТРМ министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “Татарстан Республикасының экология һәм табигый ресурслар министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе) белән” сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта “эксперт оешмалары” сүзләреннән алда “Россия Федерациясенең аккредитация турындагы законнары нигезендә илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләнгән (алга таба – эксперт оешмалары)” сүзләрен өстәргә;

Административ регламентның 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (“Российская газета”, 25.12.1993, № 237, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексы, 30.12.2001, № 195-ФЗ (алга таба – РФ КоАП) (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 07.01.2002, № 1 (1 ө.), ст. 1) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Су кодексы, 03.06.2006, № 74-ФЗ (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 05.06.2006, № 23, ст. 2381) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җир кодексы, 25.10.2001, № 136-ФЗ (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 29.10.2001, № 44, ст. 4147) (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Җир асты байлыклары турында” 21.02.1992, № 2395-1 Россия Федерациясе Законы (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 06.03.1995, № 10, ст. 823, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 10.01.2002, № 7-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 14.01.2002, № 2, ст. 133, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 02.05.2006, № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 08.05.2006, № 19, ст. 2060, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Махсус саклануччы табигый территорияләр турында” 14.03.1995 ел, № 33-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 20.03.1995, № 12, ст. 1024, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Гидротехника корылмаларының куркынычсызлыгы турында” 21.07.1997, № 117-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 28.07.1997, № 30, ст. 3589, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 26.12.2008 ел, № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 29.12.2008, № 52 (1 ө.), ст. 6249, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Су объектларын дәүләти мониторинглауны гамәлгә ашыру турында нигезләмә раслау хакында” 10.04.2007, № 219 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 16.04.2007, № 16, ст. 1921);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Су объектын файдалануга тапшыру турында карар әзерләү һәм кабул итү тәртибе турында” 30.12.2006, № 844 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 01.01.2007, № 1(2 ө.), ст. 295, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Әйләнә-тирә табигый мохитне пычрату, калдыклар урнаштыру, башка зарарлы йогынты төрләре өчен түләү һәм аларның чик күләмнәрен билгеләү тәртибен раслау турында” 28.08.1992, № 632 карары (“РФ Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыентыгы”, 07.09.1992, № 10, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Стационар һәм күчмә чыганаклардан атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыклары, җир өсте һәм җир асты су объектларына пычраткыч матдә ташландыклары, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру өчен түләү нормативлары турында” 12.06.2003, № 344 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 23.06.2003, № 25, ст. 2528, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Объектларны су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелегенә һәм су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелегенә тиешле объектларга кертү критерийлары турында” 04.11.2006, № 640 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 06.11.2006, № 45, ст. 4713);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Судан файдаланучылар өчен су объектларына матдәләрнең һәм микроорганизмнарның мөмкин булган ташландык нормативларын раслау тәртибе турында” 23.07.2007, № 469 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 30.07.2007, № 31, ст. 4088, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Судан файдалану шартнамәсен әзерләү һәм төзү турында” 12.03.2008, № 165 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 17.03.2008, № 11 (1 ө.), ст. 1033, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җирлектә су саклау зоналары чикләрен һә су объектларының яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 10.01.2009, № 17 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 19.01.2009, № 3, ст. 415);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Сусаклагычлардан файдалану кагыйдәләрен, шул исәптән сусаклагычлардан файдалануның үрнәк кагыйдәләрен эшләү, килештерү һәм раслау турында нигезләмә раслау хакында” 22.04.2009 ел, № 349 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 04.05.2009, № 18 (2 ө.), ст. 2247);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Федераль дәүләт экология күзәтчелеге турында” 08.05.2014, № 426 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 19.05.2014, № 20, ст. 2535);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында” 05.06.2013, № 476 карары (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 17.06.2013, № 24, ст. 2999, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 19.12.2002, № 1800-р әмернамәсе белән расланган Россия Федерациясенең эчке су юллары исемлеге (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 23.12.2002, № 51, ст. 5130, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.02.2009, № 197-р әмернамәсе белән расланган Аларга карата сусаклагычлардан файдалану кагыйдәләрен эшләү һәр сусаклагыч (әгәр дә алардан файдалану режимы аерым функцияләүне мөмкин итмәсә, берничә сусаклагыч, сусаклагычлар каскады яисә су хуҗалыгы системасы) өчен гамәлгә ашырыла торган сусаклагычлар (шул исәптән сыешлыгы 10 млн куб метрдан артык булган сусаклагычлар) исемлеге (“Россия Федерациясенең законнар җыентыгы”, 23.02.2009, № 8, ст. 1032, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының

“Судан файдаланучылар өчен су объектларына матдәләрнең һәм микроорганизмнарның ташларга мөмкин булган ташландык нормативларын эшләү методикасын раслау хакында” 17.12.2007, № 333 боерыгы (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 02.06.2008, № 22 (Методикага карата кушымталардан тыш бастырылган), кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының “Су законнарын бозу нәтиҗәсендә су объектларына китерелгән зыян күләмен исәпләү методикасын раслау хакында” 13.04.2009, № 87 боерыгы (“Российская газета”, 24.06.2009, № 113, (2-3 кушымталарыннан башка бастырылган), кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының “Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның җир асты байлыкларыннан файдалану буенча лицензияләр бирүне, рәсмиләштерүне һәм теркәүне, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану буенча лицензияләргә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне, шулай ук лицензияләрне үзгәртеп рәсмиләштерүне гамәлгә ашыру һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда бетерү, туктатып тору һәм чикләү турында, шул исәптән Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт һәм башка вәкаләт бирелгән органнар күрсәтмәсе буенча карарлар кабул итүгә карата дәүләт функцияләрен үтәү буенча җир асты байлыкларыннан файдалану буенча административ регламентын раслау хакында” 29.09.2009, № 315 боерыгы (“Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлар бюллетене”, 08.03.2010, № 10 (Регламентка 1, 3, 5, 7-10 кушымталардан башка бастырылган), кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең “Гидротехника корылмаларының (суднолы гидротехника корылмаларыннан кала) куркынычсызлыгы декларациясе рәвешен раслау турында” 02.07.2012, № 377 боерыгы (“Российская газета”, 03.08.2012, № 177, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

РФ Икътисади үсеш министрлыгының “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында” 30.04.2009, № 141 боерыгы (“Российская газета”, 14.05.2009, № 85, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

РФ Икътисади үсеш министрлыгының “Аккредитация аттестатв рәвешен раслау турында” 26.05.2014, № 295 боерыгы (“Российская газета”, 12.08.2014, № 180);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” 21.09.2011, № 784 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 26.10.2011, № 40, ст. 2038, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005, № 325 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 27.07.2005, № 28, ст. 0654, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 23.04.2009, № 256 карары (“Ватаным Татарстан”, 29.04.2009, № 78, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкару тәртибен раслау турында” 21.08.2014, № 603 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 26.08.2014, № 64, ст. 1987, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелегенә тиешле объектлар исемлеген раслау хакында” 31.07.2012, № 286-п (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 11.12.2012, № 91, ст. 2987);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкару буенча дәүләт функциясен үтәүгә карата административ регламентын раслау турында” 09.12.2013, № 721-п боерыгы (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы”, 06.05.2014, № 33-34, ст. 1040)”;

Административ регламентның 1.5.1 пунктындагы 2 пунктчасын “шәхси эшмәкәрләр” сүзләреннән соң “һәм гражданнар” сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 1.5.2 пунктында:

3 пунктчадагы “министр урынбасары әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

4 пунктчада “министр урынбасары әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

13 пунктчада “тикшерүләрне исәпкә алу журналында” сүзләреннән соң “(булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

Административ регламентның 1.5.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8, 9 пунктчалар белән тулыландырырга:

“8) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләр үтәлешен тикшерергә;

9) мәҗбүри таләпләрнең һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр үтәлешен тикшерергә.”;

Административ регламентның 1.6.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

“5) Россия Федерациясе карамагындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы эшмәкәрләрнең хокукларын яклау буенча Вәкаләтле Вәкилне тикшерүдә катнашырга җәлеп итәргә.”;

Административ регламентның 1.7 пунктындагы алтынчы абзацта “тикшерүләрне исәпкә алу журналында” сүзләреннән соң “(булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

Административ регламентның 2.1.1 пунктында “Интернет” челтәрендә” сүзләрен “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 2.3.1 пунктындагы өченче абзацны “кече предприятиеләргә карата” сүзләреннән соң “илле сәгатьтән артык булмаган” сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 2.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.3.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

“2.3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер мәртәбәдән артык булмаган ешлыкта үткәрелә”;

Административ регламентның 2.4.1 пунктындагы җиденче абзацта “министр урынбасары әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 2.4.2 пунктындагы 3 пунктчасында “министр урынбасары әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 2.5 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” 21.09.2011, № 784 карары белән расланган”;

2.2 таблицаны төшереп калдырырга;

Административ регламентның 2.7 пунктындагы өченче абзацында “ун” көн сүзләрен “ун эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 3 таблицасында “Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый актлар” графасында:

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.12.2006, № 801 карары белән расланган Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау буенча дәүләт контролен һәм күзәтчелеген башкару турында нигезләмәнең 2 пункты” сүзләрен “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану хакында” 05.06.2013, № 476 карары белән расланган Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә” сүзләре белән алмаштырырга;

“Җир асты байлыклары турында” 21.02.1992, № 32395-1 Россия Федерациясе Законының 9, 11 статьялары” сүзләрен “Җир асты байлыклары турында” 21.02.1992, № 2395-1 Россия Федерациясе Законының 9, 11 статьялары” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 4 таблицасында “Документ рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт” графасында:

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Стационар һәм күчмә чыганаклардан атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыклары, җир өсте һәм җир асты су объектларына пычраткыч матдә ташландыклары, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру өчен түләү нормативлары турында” 12.06.2003, № 344 карары” сүзләрен “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Стационар һәм күчмә чыганаклардан атмосфера һавасына пычраткыч матдә ташландыклары, җир өсте һәм җир асты су объектларына, шул исәптән үзәкләштерелгән су бүлү системаларыннан пычраткыч матдә ташландыклары, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру өчен түләү нормативлары турында” 12.06.2003, № 344 карары” сүзләре белән алмаштырырга;

“РФ Хөкүмәте карамагындагы геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча комитетның “Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турында нигезләмә хакында” 10.09.1002 № ВО-61/2296 хаты” сүзләрен “Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының “Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның җир асты байлыкларыннан файдалану буенча лицензияләр бирүне, рәсмиләштерүне һәм теркәүне, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану буенча лицензияләргә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне, шулай ук лицензияләрне үзгәртеп рәсмиләштерүне гамәлгә ашыру һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда бетерү, туктатып тору һәм чикләү турында, шул исәптән Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт һәм башка вәкаләт бирелгән органнар күрсәтмәсе буенча карарлар кабул итүгә карата дәүләт функцияләрен үтәү буенча җир асты байлыкларыннан файдалану буенча административ регламентын раслау хакында” 29.09.2009, № 315 боерыгы” сүзләре белән алмаштырырга;

“Сертификацияләү органнарының һәм сынау лабораторияләренең (үзәкләренең) аккредитация аттестатлары һәм аңа кушымталар рәвешен

раслау турында” 24.09.2012, № 618 боерыгы” сүзләрен “РФ Икътисади үсеш министрлыгының “Аккредитация аттестаты рәвешен раслау турында” 26.05.2014, № 295 боерыгы” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.1.1 пунктындагы дүртенче абзацта “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.1.3 пунктында:

икенче абзацта “ТР ЭТРМ боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

өченче абзацта “әмернамәсе” сүзен “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

бишенче абзацта “боерык (әмернамә)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.1.4 пунктында:

беренче һәм өченче абзацта “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

бишенче абзацта “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.1.6 пунктындагы бишенче абзацта боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.2.2 пунктындагы “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентны 5.2.3 пунктындагы өченче абзацта “министр (министр урынбасары) әмернамәсе белән” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе) белән” сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентның 5.2.4 пунктындагы җиденче абзацта “тикшерүләрне исәпкә алу журналында” сүзләреннән соң “(булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

Административ регламентның 5.3.1 пунктындагы дүртенче абзацта “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.3.3 пунктындагы өченче абзацта “боерык (әмернамә)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.3 пунктындагы “5.4.5” пункты номерын “5.3.5.” итеп үзгәртергә;

Административ регламентның 5.4.5 пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

Административ регламентның 5.4.3 пунктында:

беренче абзацта “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга);

өченче абзацта “боерык (әмернамә)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.4.4 пунктында:

өченче абзацта “электрон сан имзасы белән” сүзләрен “көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән” сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

алтынчы абзацта “әмернамәсе” сүзен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 5.4.6 пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

Административ регламентның 6.5 пунктындагы икенче абзацта “министр (министр урынбасары) әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре белән алмаштырырга);

Административ регламентның 7.4 пунктында:

беренче абзацта «Шикаятькә җавап бирелми” сүзләреннән соң “яисә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирелми” сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта “шикаятьне җибәрүченең, почта адресы” сүзләрен “шикаять җибәрүченең, яки почта адресы” сүзләре белән алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ – әгәр дә шикаятьтә, элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә, аның асылы буенча берничә тапкыр язмача җавап бирелгән сорау булса һәм бер үк вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә (аталган шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки бер үк вазифаи затка җибәрелгән очракта) (мөрәҗәгать итүчегә язышуларны бетерү турындагы карар хакында хәбәр ителә);

Административ регламентның 7.6 пунктында “тиешле гарызнамәне язмача” сүзләреннән соң “яки электрон” сүзләрен өстәргә.